**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле
авылында 2024 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

**18.11.2023ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Текмәле авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән, күпбалалы гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Урам яктыртуны тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урам яктыртуны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр сатып алу һәм алыштыру);

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре)

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы; 51 нче йорт, Текмәле авылы, Ишкәй урамы, 15 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:// pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина